ХАЛЫККА – СЫЙФАТ

Түбән Камада узган елга йомгак ясадылар

> 2

КЫШТАМЫ ГАЕП?

Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр «тешли»

> 2



КУРКЫНЫЧ МАТУРЛЫК

Яшәрәм дип... пычак астына

> 4

ӨМЕТ ЙОЛДЫЗЫ

Камиләбез бу юлы да сынатмас

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 22 (28795) | Сишәмбе | 15 февраль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

УКЫТУЧЫГА СҮЗ ӘЙТМӘГЕЗ...

Борчыган мәсьәлә

Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары, депутат Борис Чернышов укытучыларны һөҗүмнәрдән яклау оешмасы булдырырга тәкъдим иткән. Аның фикеренчә, бүген педагоглар үзләренә карата хөрмәт тоймый. Мәгариф системасына тәнкыйть кенә түгел, педагогларга ярдәм дә кирәк. Мөгаллимнәрне яклаучы вәкаләтле вәкил булдырып кына аксаган тәрбияне төзәтеп булырмы?

Борис Чернышов әйтүенчә, күпчелек укытучылар борчуларын кемгә барып сөйләргә белми. Директорлар дәгъва белдергән өчен эштән куарга мөмкин, түрәләр бәхәсләрне читкә чыгармаячак, федераль дәрәҗәдә исә аларны ишетмиләр. Шуның өчен эштән нигезсез җибәрелгән укытучыларның хокукларын яклый торган институт кирәк дип саный ул.

Татарстан прокуроры Илдус Нәфыйков та коллегия утырышында мәктәптәге вазгыятькә карата борчылырлык фикерләр әйтте. «Балалар укытучыларга охшарга тырышудан туктады. Өлкән буын яхшы хәтерли: элек алар абруйлы, киңәшче кебек иде. Укытучы фикеренә һәрвакыт колак салдылар. Хәзер бит укытучылар мәктәп программасын сөйли һәм азынган укучыга тавыш күтәрергә дә курка. Мондый шартларда нинди тәрбия турында сүз булырга мөмкин?» – диде Илдус Нәфыйков.

Прокурор фикеренчә, мәгариф системасы күп еллардан бирле рейтинг белән бәяләү басымында. Балалар белән эш ике төркемгә бүлеп башкарыла. Гадәттә игътибар йә сәләтле, йә тәрбиягә авыр бирелүче балаларга бирелә. Бу төркемнәрдән читтә калучылар да бар һәм алар моны социаль гаделсезлек дип кабул итә. Мәктәпләрне элиталы һәм гади мәктәпләргә (хәтта мәктәп эчендә элиталы сыйныфларга) бүлү дә еш кына тискәре йогынты ясый. Беренчеләргә игътибар җитсә, икенчеләре үзләрен кирәксез хис итә. Кайбер балаларга укытучыларның да, әти-әниләрнең дә вакыты калмый. Нәтиҗәдә балаларны интернет белән урам тәрбияли. Бу вазгыятьне үзгәртергә кирәк.

Казандагы 18 нче мәктәп укытучысы Альбина Яруллина укытучыларны яклау кирәклеге турында күптән уйлана.

– Иң яклаучысыз һөнәр ияләре дип укытучылар һәм медицина хезмәткәрләрен саныйм. Моны күптән үзгәртергә вакыт. Без бик куркыныч заманда яшибез, хәтта мәктәп укытучысына да яклау һәм ярдәм кирәк. Укытучыларга теләсә кемнең теләсә нәрсә әйтергә хакы юк. Шикаять язу, видеога төшерүләр катгый рәвештә тыелырга тиеш. Мондый адымга барыр алдыннан һәр укучы, әти-әни ныклап уйлансын иде. Замана баласы, әти-әниләр бик күп белә. Әлбәттә, моңа интернет ярдәм итә. Бу начар әйбер түгел. Хокукларны белергә кирәк анысы. Тик андый белемнәр кайчак файдага түгел. Ничек укытырга, тәрбияләргә, дәваларга кирәклеген хәзерге заман кешесе белә. Тик берәүнең дә бу эшкә алынасы килми. Әгәр вәкаләтле вәкил, институт булдырылса, укытучылар шат булыр иде. Дөрес, укытучы да ялгышырга мөмкин. Әмма тупас, авыр холыклы кешеләр мәктәптә озак эшли алмый. Алар барыбер китәчәк. Бу һәр эштә дә шулай. Белем бирү системасын яңартып, укытучыларны кайгыртып торсыннар, аның психологик халәте турында да онытмасыннар иде, – ди Альбина Яруллина.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Егерме елга якын мәктәптә эшләгән Альбина Киселевага ярты ел элек мәктәптән китәргә туры килгән. Әйтүенчә, яхшы хезмәт хакы түләсәләр дә, укытучы булып башка эшләмәячәк.

– Мондый институтны булдырырга кирәк. Укытучы якланмаган, көчсез. Бездә укучыга да, әти-әниләргә дә сүз әйтергә ярамый. Үсмерләрнең холкы бик катлаулы. Тупас сүзләр әйтергә, кимсетергә күп сорамыйлар. Башлангыч сыйныфта алай түгел. Әниләр укытучыны хөрмәт итәргә өйрәтми дип уйлыйм. Бер-ике бала гына табып, иркә, эгоист итеп үстерәләр. Элек алай булмаган бит. Киләчәктә тагын ничек булыр? – ди Альбина Киселева.

Юрист-укытучы Рәшид Нәҗметдиновка укытучыларны еш якларга туры киләме икән?

– Укытучыны кемнән якларга җыеналар? Әти-әнидәнме, укучыданмы? Мондый институт төзү кирәкми. Артык оешма бу. Укытучыларны якларга мәктәп җитәкчелеге бар. Әгәр ул бу эшне бозса, укытучыны профсоюз, хезмәт инспекциясе яклый ала. Әти-әниләрдән, балалардан якларга мәктәп җитәкчелеге, прокуратура, хокук органнары булыша. Монда бары мәктәп җитәкчелеге һәм башкаларның укытучыларны яклау өстендә эшләве генә кирәк. Безгә дә педагогларны якларга туры килә. Күбрәк мәктәп җитәкчелегенә карата дәгъва белдерәләр. Әти-әниләрнең миңа укытучыдан зарланып килгәннәре юк, – ди Рәшид Нәҗметдинов.

КФУ галиме, педагогика фәннәре докторы Җәүдәт Хөсәенов, укытучыларны якларга кирәк, ди.

– Элек укытучы дәрәҗәле иде, хәзер аны кешегә дә санамыйлар. Шуңа күрә яклаучы институт булдыру – бик яхшы фикер. Бу ышанычлы калкан булсын иде. Белем бирү тәрбиядән башлана. Шуңа күрә мәктәпләргә тәрбияне кайтарырга кирәк, – ди Җәүдәт Хөсәенов.

Сәрия МИФТАХОВА

Татарстан – дүртенче урында

Татарстан узган елда тормыш сыйфаты буенча Россия төбәкләре рейтингында дүртенче урынга чыккан. Хәер, республика бер ел элек тә шушы урынны алган булган, әмма хәзер күрсәткечләрен яхшырткан. «РИА Новости» тикшеренүе нәтиҗәләре шуны күрсәтә.

Узган елда лидерлар бишлегендә бер төбәк кенә үзгәргән: Краснодар крае, Белгород өлкәсен артта калдырып, бишенче урынга чыккан. Калган дүртлек – үзгәрешсез. Боларга Мәскәү, Санкт-Петербург, Мәскәү өлкәсе һәм Татарстан керә. Шунысы кызык: рейтингта иң алда урнашкан өч төбәктә тормыш сыйфаты буенча күрсәткечләр 2020 елдагы белән чагыштырганда берникадәр начарайган, бары Татарстанныкы гына яхшырган. Рейтингны төзегәндә белгечләр тормыш шартлары һәм социаль өлкәдәге вазгыять буенча 67 күрсәткечне исәпкә алган. Калмыкия, Ингушетия, Курган өлкәсе, Алтай һәм Бурятия Республикалары һ.б. исемлектә иң соңгы урыннарда калган.

Сыер һәм кәҗә өчен

Быел Татарстанда шәхси ярдәмче хуҗалыкларга 418 миллион сум акча бирү күздә тотыла. Бу хакта Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының кече хуҗалыкларны үстерү бүлеге башлыгы Александр Молокин белдергән. Аның әйтүенчә, узган елда барлыгы 50730 хуҗалыкка 403,7 миллион сумнан артыграк күләмдә субсидия бирелгән. Субсидияләрне сыер һәм кәҗә асраучылар – быел барлыгы 48387 хуҗалык алачак.

Бүлек башлыгы аныклап үткәнчә, төп ярдәм савым сыер асраучыларга тәгаенләнә. Аерым алганда, бер сыер асраучы хуҗалыкка – 2 мең сум, ике сыер тотучыга – һәркайсына 3әр мең сум, өч һәм аннан күбрәк сыер асраучыга 4әр мең сум биреләчәк. Тик бер шарты бар: 500 сумга ветеринария чаралары үткәрү буенча килешүгә кул куярга кирәк. Моның өчен һәр сыерга 300әр сум күләмендә өстәмә субсидия түләнә.

Татарстанда 468 мең шәхси хуҗалык исәпләнә.

Ипотека кыйммәткә төшә

Казанда торакны ипотекага сатып алу отышлыракмы, әллә аны арендага алып торумы – белгечләр әнә шул сорауга җавап тапкан. Тикшеренү нәтиҗәләре буенча Татарстан башкаласында ипотекага торак сатып алу бәясенең арендалауга караганда 1,3–1,6 тапкыр кыйммәткәрәк төшүе ачыкланган.

Казанда иң кыйммәтле ике бүлмәле фатирлар рейтингы буенча, урта сроклы ипотекага алынган яңа торак 41,7 (беренчел базарда) һәм 44,5 миллион сумга (икенчел базарда) төшсә, шушы ук срокка аренда бәясе 32 миллион сумны тәшкил итә. Ә инде иң арзанлы торак буенча аренда бәясе – 3,1 миллион сум, ипотекага сатып алынган фатир бәясе – 4,9 миллион сум һәм 4 миллион сум.

Вазгыять

COVID читлегендә

Саннарның сагайткан чагы. Әле узган атна башында коронавирус йоктырып авыручылар күрсәткече бер мең – мең ярым тирәсендә булса, хәзер инде өч меңнән артык кеше турында сөйлибез. Гомумән, инфекция йоктыручылар саны арту Россиянең 74 төбәгендә күзәтелә. 33 төбәктә ул ил буенча күрсәткечтән зуррак та әле. Медицина тармагы эшендә дә, җәмгыятьтә дә киеренкелек саклана.

Ярдәм көткәннәргә – булышырга, медицина хезмәткәрләре турында да онытмаска. Хөкүмәт йортындагы «шимбә киңәшмәсе»ндә Татарстан Президенты вазгыятьне кулдан ычкындырмас өчен барысын да эшләргә кирәк булуын әйтте.

– «Омикрон»ның таралуы чирләүчеләр санының артуына китерде. Үткән атнада авыручылар күрсәткече ике мәртәбә артты, бу исә медицина тармагының беренчел звеносына эш өстәде, – диде республика җитәкчесе. – Татарстанда булган чикләү чараларының барысы да үз көчендә кала. Хезмәт коллективларында барлык санитар-эпидемиологик таләпләрне үтәргә, мәктәпләрдә иртәнге «фильтр» эшен катгый контрольдә тотуны дәвам итәргә кирәк.

Бар авырлык – сырхауханәләргә. Алар икенче атна дәвамында ялсыз – дүшәмбедән якшәмбегә кадәр тулы составта эшли. Республиканың оператив штабына мөрәҗәгать итүчеләрнең санын киметү, медицина хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтү кебек мәсьәләләрне хәл итү ысулларын карарга кушылды.

– Кеше болай гына хастаханәләргә шалтыратмый ул. Йә чирли, йә башка сораулары була. Аларга вакытында җавап бирергә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Район башлыклары да урыннардагы хәлне контрольдә тотсын һәм медицина вәкилләренә кирәк ярдәмне күрсәтсен.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Хәер, ак халатлыларга эшне азрак киметү өчен чаралар күрелә башлады инде. Әйтик, электрон «больничный». Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин әйтүенчә, хәзер «больничный» кәгазен читтән торып яптыру мөмкинлеге бар. Моның өчен «122» телефон номерына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

– Бу – «больничный» кәгазен бастыра торган типография булырга тиеш түгел. Кешенең соравы, консультациягә ихтыяҗы бар икән, авыру янына барып кайту турында да онытмаска кирәк, – диде бу уңайдан Рөстәм Миңнеханов.

САН

Бер тәүлек эчендә чир йоктыручылар саны буенча Татарстан Россия төбәкләре арасында 12 нче урында тора.

Узган тәүлектә 3970 кешедә COVID-19 ачыкланган. 362 кеше хастаханәдә дәвалана.

Татарстанда 2434757 кешегә вакцинация ясалган, шуларның 1896321е прививканың икенче дозасын алган. Кабат вакцинацияне 221 мең кеше узган.

Сүзгә-сүз

Дмитрий НЕСВЕТОВ, «Опоры России» берләшмәсе эксперты:

Бүген кредитны иң кирәкле дип саналган әйберләргә генә рәсмиләштерергә кирәк. Югыйсә ахыры аянычлы булып бетәргә бик мөмкин. Түләп бетерелмәгән бер әҗәт икенчесен тартып китерә, шулай итеп чокырга тәгәрәвеңне сизми дә каласың. Әйберләрнең һәм финанс ресурсларының бәясе артып торганда, бу бигрәк тә куркыныч.

«Известия» газетасыннан

ТАТАРСТАНДА – МИГРАЦИЯ

Узган ел Татарстанда чит илдән килгән һәм гражданлыгы булмаган 256170 кеше миграция исәбенә алынган. 7598 кеше Россия гражданлыгы алган. Эш өчен 36 меңнән артык патент рәсмиләштерелгән.



Саклык акча арткан

Татарстан банкларында халыкның чама белән 743,7 миллиард сум акчасы саклана. Бер ел эчендә бу сумма 12,2 процентка арткан. Россия Үзәк банкының Татарстан буенча бүлеге матбугат хезмәте агымдагы елның 1 гыйнварына шундый мәгълүматлар китергән. Халык акчаны сумнарда күбрәк саклый: банкка салынган акчаның 84,9 проценты (631,5 миллиард сум) шуңа туры килә. Бу сумма бер елда 10,8 процентка ишәйгән. Чит ил валютасындагы саклык акча күләме бер елда 20,7 процентка (112,1 миллиард сум) үскән.

Республиканың юридик затлар депозитларында акча узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 26 процентка артып, 570,5 миллиард сумнан артып киткән. Шәхси эшмәкәрләр счетындагы акча – 23 миллиард сумга, оешмалар акчасы 276,8 миллиард сумга җиткән.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ДАВЫЛ КӨТКӘНДӘ

Үткән атна ахырында дөньякүләм мәгълүмат кырында зур бомба шартлады: АКШ Президенты Байден, разведка мәгълүматларына таянып, 16 февраль көнне Россиянең Украинага һөҗүм итәчәген белдерде. Сүз ниндидер бер блогер авызыннан гына түгел, дөньякүләм держава лидеры авызыннан чыкканга күрә, зур кайтаваз тудырды.

Илләр бер-берсен уздырып, үз илчелекләрен һәм гражданнарын Украинадан эвакуацияли башлады. Көнбатыш дәүләтләре лидерлары ашыгыч рәвештә Путин белән телефон элемтәсен таләп итте. Байден Кремльгә дүшәмбе көнне шалтыратырга тиеш иде, сөйләшүне алга күчерделәр. Аралашу әллә ни яңалык өстәмәде: ике як та элек әйтелгән сүзләрне генә кабатладылар. Бөекбританиянең оборона министры – күптән түгел генә Мәскәүдә Шойгу белән очрашып кайткан Бен Уоллес та сугыш башлану куркынычы зур булуын белдерде. Киевта үзләрен канлы конфликтның якындагы көннәрдә старт бирәчәгенә баштарак ышанып бетмәгән кебек тоттылар, әмма гомуми психозга Зеленский да иярде: Байден белән телефоннан сөйләште, аны Украинага ашыгыч визит белән килергә чакырды. Аның фикеренчә, андый визит сугыш башлану ихтималын киметергә тиеш иде.

Төньяк Атлантик блок лидерлары да ашыгыч рәвештә үзара элемтәгә керде. Байден, Шольц, Макрон, Джонсон, Дуда, Драги, Столенберг, Трюдо, фон дер Ляйен һәм Мишель катнашында гадәттән тыш телефон конференциясе оештырдылар. Кыскасы, ял көннәрендә зур сәясәт өермәсе купты. Фонд базарында соңгы сәүдә сессиясендә Россия акцияләре һәм рус сумы шулай ук мәтәлчек атты. Әлегә бер пуля атылмаса да, финанслар егылды. «Фейсбук»та «Российская газета»ның икътисад күзәтүчесе Яков Миркин гаскәрләр чикне үтеп чыккан очракта булачак куркыныч сценарийны фаразлады. Аның фикеренчә, банкоматлар акча бирүдән туктаячак, сум кискен түбәнгә очачак, биржа сәүдәсе туктатылачак, кибетләрдә чиратлар тезеләчәк, бәяләр (аңлашыла инде) космик тизлектә югарыга очачак.

Әмма Кремльдә сугыш башламаячакларын өзеп әйтеп торалар. Хәзерге вакытта, әлбәттә, Украина чигендә масштаблы хәрби өйрәнүләр бара, Россия гаскәрләре чик сызыгына бик якынайды, Белоруссиядә дә, Кара диңгездә дә ракеталар оча, вертолетлар күкне иңли. Бер провокация хәлне тамырдан үзгәртергә ихтимал. Тарихта берәү дә сугыш башларга теләмәгәндә дә, зур суеш оештырылуның мисаллары бар. Андый конфликтның технологиясе яхшы эшләнгән. Шуңа күрә беркем дә өзеп кенә сугыш булмас дип әйтә алмый. Шулай да Ак йортның милли куркынычсызлык буенча киңәшчесе Джейк Салливан якшәмбе кичендә янки разведкасының сишәмбе-чәршәмбедә үк сугыш башлана дигән хәбәрен росларга ашыкмауларын белдерде. Аның фикеренчә, АКШ җитәкчелеге сугыш көтмәгәндә башланмасын өчен барысын да эшләячәк. Конфликт озак эленеп тора алмый, әлбәттә. Якындагы көннәрдә өйрәнүләрне төгәлләп, гаскәрләрне казармага кайтарырга кирәк булачак. Бу вариант тормышка ашмаса, сугыш котылгысызлыгы артачак. «Ватаным Татарстан» һәрвакытта да сугышның төп сәбәбе финанс кризисы икәнен әйтеп килде. Безнең фикерне «Би-би-си» да кабатлый. Аның сайтында «Көнбатыш лидерлары үз проблемаларын Украина тирәсендәге кризис ярдәмендә чишә алалармы?» дигән подкаст эленеп тора. Әлегә вазгыять шундый: Украинада халыкны эвакуацияләү планы эшләнде, Байден Мәскәүне сугыш башлаган очракта «кискен җавап» белән куркыта, Германия канцлеры Олаф Шольц сишәмбедә Путин белән очрашырга җыена. Украина күге очкычлар өчен ябылды.

Россиядә

БАШЛАНМАГАН СУГЫШ ДАВЫЛЫ

Россиянең эчке тормышына сугыш ихтималлыгы турындагы хәбәрләр торнадо тизлеге белән бәреп керде. Финанс спекулянтлары сум белән бәйле позицияләрне яптылар, дөнья биржаларында Россия бизнесының кәгазьләрен күпләп сату башланды. Вазгыять бер көн эчендә үзгәрде. 8 февральдә, пәнҗешәмбе көнне, спекулянтлар, сумның үсүенә исәп тотып, 15443 контракт төзегән булсалар, җомгада инде хәл үзенең кире ягына үзгәрде. Бу юллар дүшәмбе иртәсендә языла, биржалар әлегә ачылмаган, сәүдә башланмаган, шуңа күрә паника дәвам итәме-юкмы икәнен әйтү кыен.

Россия бизнесы өчен тагын бер күңелсез яңалык бар: чит ил банклары рус бизнесын кредитлауны туктатты. Чит ил банкларының россияле компанияләргә һәм физик затларга биргән кредиты 121 миллиард долларга җитә икән. Чит ил банкларында исә россияле клиентларның 128 миллиард доллар акчасы саклана ди. Россия икътисадының гомуми тышкы әҗәте (дәүләт бурычларын да исәпләп) 478 миллиард долларга җитә. Күрәбез: икътисад чит ил кредитлары белән тыгыз бәйләнеп беткән. Халыкара финанс оешмалары кредит бирүдән туктаса, ил эчендәге бизнес җәмәгатьчелегенә бу нык тәэсир ясаячак. Әмма бер нәрсә бар: иң кискен санкцияләр кертелсә дә, Россияне халыкара түләүләр системасы SWIFTтан өзмәсләр, мөгаен. АКШның бу таләбен Европа дәүләтләре кире кага. Вәләкин эре Россия банклары валюта блокадасына алыначак, монысы тәгаен.

Россия финансларында әлегә «җәһәннәм санкцияләре»ннән башка да эш катлаулы. Үзәк банк, без үткән атна башында фаразлаганча, төп ставканы 9,5 процентка кадәр күтәрде һәм моның соңгы күтәрелеш түгеллеген рәсми рәвештә әйтеп тора. Бу ел ахырына кадәр төп ставка ике урынлы сан белән бәяләнә башлаячак, 11 процентка җитәр, диләр. Бу гадәттән тыш хәлләр булмыйча, эшләр яхшы барганда шулай көтелә. Икътисадчы Яков Миркин сугыш башланган очракта, төп ставка кискен өскә күтәреләчәк, инфляция ике урынлы сан белән бәяләнәчәк дип фаразлый. Бизнесның хәлен шуннан күз алдына китерегез: чит ил банкларыннан түбән процентлы кредитлар алу мөмкинлеге инде бетеп бара, үзебездәге ставка белән кредит алсаң, бөлү котылгысыз. Менә бит танк чылбырлары әйләнгән саен, инфляция ничек котыра. Шуңа күрә өметләник инде: хәрби техниканың моторлары сүндерелер, киеренкелек сүрелер. Югары җитәкчелек тә зур икътисади түнтәрелешне теләми торгандыр. Мускуллар уйнатылды, шул җитәр. Сугыш башлана калса, Киев пропагандасы, аны Мәскәү башлады, дип шаулаячак, Кремльдә, старт төймәсенә украиннар басты, диячәкләр, әлбәттә. Вариантларның икесе дә безгә санкцияләр вәгъдә итә барыбер.

ЭШЛӘГӘНГӘ АШ КИРӘК

tatarstan.ru

Көндәлектә кулланган әйберләрнең барысының да чишмә башы Түбән Камадан икән. Бензин, кием-салым, көнкүреш техникасы, дисеңме. Түбән Кама район һәм шәһәр Советларының 2021 ел эш нәтиҗәләренә багышланган утырышында башкарма комитет җитәкчесе Рамил Муллин һәммәсенә шул хакта искә төшерде. Утырыш Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында үтте. Шәһәр нинди хыяллар белән яши, Түбән Каманың «акыллы баш»лары каладан ник китә дә юлны кардан чистарту өчен кемне көтәргә кирәк? Утырышта ирешкән уңышларга сөенделәр һәм борчыган урыннарга төртеп күрсәттеләр.

Рамил Муллин әйтүенчә, узган ел Түбән Кама өчен сынау елы булды. Чире-коронавирусы да бетмәде, икътисадны да күтәрү кирәк.

– 2021 ел шәхсән минем өчен дә үзенчәлекле булды. Җитәкчелекнең ышанычы мине кабат Түбән Камага кайтарды. Яңа команда белән алдыбызда торган бурычларга җавап бирүнең әһәмиятен тоеп эшлибез, – дип, ул Татарстан җитәкчесе һәм элеккеге башлык Айдар Метшинга рәхмәтен җиткерде.

Түбән Кама икътисадының нигезен нефть-химия, нефть эшкәртү, энергетика, кече һәм урта бизнес тармаклары тотып тора. Шәһәр өчен узган елның уңышлы-уңышсыз булуын шул юнәлешләрдәге саннарга карап чамаларга буладыр.

Әйтик, «Татнефть» компаниясе уңышлары белән сөендергән, берничә инвестиция проектын гамәлгә ашырган. «ТАИФ-НК»да авыр калдыкларны эшкәртү комплексы файдалануга тапшырылды. Тагын бер мөһим вакыйга – Түбән Камадагы зур предприятиеләрнең «Сибур»га кушылуы. Сүз уңаеннан, Түбән Кама «Нефтехим» җәмгыяте былтыр 2,7 млн тонна продукция җитештергән. Бу – предприятие өчен рекордлы сан. Узган ел республика бюджетына компания эшчәнлегеннән 11,4 млрд сум акча кергән.

Кече һәм урта бизнестан килгән керем дә мактанырлык. Узган елгы товар әйләнеше 54 млрд сумны тәшкил иткән.

– Бездә ике индустриаль һәм бер сәнәгать паркы бар. Монда инвесторларга барлык шартлар тудырылган. 21 компания ТОСЭР резиденты булды. Быел тагын җиде резидент җәлеп итәргә ниятлибез, – ди Рамил Муллин.

Мәшәкатьләр дә җитәрлек. Әйтик, авырткан җир булып сәламәтлек саклау тармагы кала. Рамил Муллин сүзләренчә, сырхауханәләрдә табиблар белән тәэмин ителеш 45,8 процентны тәшкил итә. Кадрларга ихтыяҗ булачак әле, ди ул, чөнки быел Түбән Камада Ашыгыч медицина үзәген кулланышка тапшыру күздә тотыла.

Шәһәрнең төп байлыгы – аның кешеләре. Рамил Муллин чыгышында аларга да рәхмәтен әйтте.

– Спорт киеме, мебель, көнкүреш техникасы, автомобиль панельләренең, су эчә торган стаканнарның нәрсәдән ясалуы турында еш уйланабызмы? Болар барысы да Түбән Кама полистиролыннан ясала. «ТАНЕКО» һәм «ТАИФ-НК» бензинын кулланабыз, Түбән Кама шиннарын сатып алабыз. Сагызда да безнең каучук! Боларны җитештерүчеләр дә – безнекеләр, Түбән Кама кешеләре. Бу – безнең байлыгыбыз, – диде башлык.

Матди булмаган байлыкны югалту куркынычы да бар. Түбән Кама шәһәр Советының утырышта катнашкан иң яшь депутаты Алия Миңнуллина, инфраструктура объектлары булмау сәбәпле, яшьләрнең һәм сәләтлеләрнең шәһәрдән китүенә зарланды. Татарстан Президенты исә моның табигый күренеш булуына ишарәләде. Моны бина төзеп, үзәк ачып кына да хәл итеп булмый.

– Яшьләр читкә китә. Шундый ук бәла Әлмәт, Чаллыда да. Җитди карарлар кабул итмәсәк, бу дәвам итәчәк. Бу эш комплекслы якын килүне таләп итә. Түбән Камадан китәчәкләр, чөнки сездә сәләтле кешеләр күп. Аларга бит үсәргә кирәк. Илсур Метшин (Казан мэры. – **Ред.**) да китте бит. Иң мөһиме – күпләп китү булмасын, – диде республика җитәкчесе.

Гомумән алганда, Рөстәм Миңнеханов Түбән Каманың Татарстан үсешенә керткән өлеше зур булуын ассызыклады. Шелтә дә белдерде. Баксаң, Түбән Каманың 12 меңләп кешесе МРОТ күләменнән дә азрак хезмәт хакы ала икән.

– Хезмәт хакы буенча сез республикада өченче урында торасыз. Әмма III квартал нәтиҗәләре буенча районның 60 предприятиесе минималь хезмәт хакыннан да кимрәк түли. 12 меңгә якын кеше түбән керем ала. Сәбәпләрен ачыкларга кирәк, – диде Президент.

Республика җитәкчесе торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дә хәл итәсе мәсьәләләр күплеген әйтте. Халыкның урам-юлларны чиста тоту буенча зарлары да күп. Алар урынлы дип саный Президент.

– Мин килгәч, юлларны чистарткансыздыр инде. Менә миннән дә файда бар икән бит! – диде Президент, уенын-чынын бергә кушып. – Халык мондый уңайсызлыкны тоярга тиеш түгел.

Түбән Камада Рөстәм Миңнеханов районның социаль-икътисади үсеше мәсьәләсе буенча киңәшмә уздырды. Президент 5 еллык социаль-икътисади үсеш программасын эшләргә тәкъдим итте. Аның фикеренчә, программага бизнес-структуралар да җәлеп ителергә тиеш, чөнки шәһәр эре сәнәгать предприятиеләрен хезмәт ресурслары белән тәэмин итә.

Бу көнне Түбән Камада күпфункцияле үзәк тә ачылды. Ул шәһәрдәге бер сәүдә үзәгенең бишенче катында урнашкан. Сүз уңаеннан, бу – Татарстанда ачылган күпфункцияле үзәкләрнең 61нчесе. 2015 елдан башлап, алар 28,7 млн тапкыр хезмәт күрсәткән, шуларның 6,9 миллионы 2021 елга туры килә. Күпфункцияле үзәктә документларны кабул итү-бирү буенча 11 бүлек эшли, мөрәҗәгать итүчеләргә көн саен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең 260лап төреннән файдалану мөмкин. Көн саен 200гә якын кешене кабул итәргә әзерләр.

Җылыга түлисе, салкынга түзәсе

Яшәеш

Февраль аена килгән торак-коммуналь түләүләр квитанциясе күпләрне аптырашта калдырды. Берәүләр 4 мең сум түлисе урынга – 6 мең, икенчеләр 3 мең урынына 7 мең сум акча килгәнгә зарлана. Бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та хәбәрдар. Шимбә көнне үткән республика киңәшмәсендә ул Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллинга моның нидән килеп чыкканлыгын ачыкларга кушты.

– Соңгы арада гыйнвар аена килгән түләүләрнең артуыннан зарланучылар турында газеталарда, социаль челтәрләрдә күп кенә язмалар чыкты. Аеруча Казан, Чаллы, Түбән Кама халкы канәгатьсезлек белдерә. Без битараф кала алмыйбыз. Министрлык идарәче һәм ресурс белән тәэмин итүче оешмалар белән берлектә һәр очрак буенча проблеманы ачыкларга тиеш. Халыкка аңлатыгыз, әгәр хаталар китә икән – аны тиз арада хәл итегез, – диде Президент.

Министр Марат Айзатуллин шунда ук бу хәлгә ачыклык кертте. Аның сүзләренә караганда, тарифлар шул килеш калды. Түләүләрнең артуы температура төшү белән бәйле икән.

Казанның Әмирхан урамында яшәүче Нәсимә Вәлиева да җылылык өчен түләүнең артып килүенә зарлана.

– Ел саен бер үк хәл. Кыш айларында бәяне арттыралар. Ике бүлмәле фатир өчен 7800 сум түләү килгән. Шуның 3200 сумы җылылык өчен. Нишләргә дә белгән юк инде. Идарәче оешмага баргач, алар көннәрнең салкын торуын әйтә. Шунлыктан җылылык тоту күләме арткан, дип аңлаталар. Без түлисен кеше түләмәс инде. Уңай җавап ишетмәгәч, түләргә булдым, – ди ул.

Зарланучыларның күбесенең фатирларына җылылык үзәкләштерелгән система буенча килә. Шәхси җылыту казаны булганнар исә түләү квитанциясендә үзгәреш күрмәгән.

– Декабрь аенда коммуналь хезмәтләр өчен 3900 сум түләү килгән иде. Гыйнвар аенда да шул сумма. Зарланырлык урын юк. Күпме тотабыз – шуның өчен түлибез. Барлык йортларга да шәхси җылыту казаны куелса, халык акчасын янга калдырыр иде, – дигән фикердә Казанның Завойский урамында яшәүче Фирүзә Шакирова.

Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге башкарма директоры Дмитрий Романов та квитанциядәге суммаларның алдагы айлардан күпкә артыграк булуын һава торышына бәйләп аңлата.

– Әгәр кыш җылы икән, түләүләр кими. Салкын икән, киресенчә, – ди Дмитрий Романов. Җылылыкны көйләү өчен махсус җиһаз урнаштырырга кирәк. Ул булса, һава температурасы минустан плюска күчкәндә, җылылыкны хәтта 25–30 процентка кадәр янга калдырырга була. Фатирда кызу булганда, батареяларга кысып кую өчен махсус кран урнаштырылган икән, җылылыкны көйләргә мөмкин. Ишекне һәм тәрәзәләрне дә җылытырга кирәк.

Дмитрий Романов, идарәче оешма җибәргән квитанциядә зур суммалар булса, нишләргә кирәклеген дә аңлатты.

– Әгәр идарәче оешма квитанциядә гомуми йорт өчен тотылган җылылыкны да күрсәтә икән, бу очракта андагылардан язмача аңлатма сорагыз. Шулай ук йорттагы җылылык исәпләгече күрсәткечләрен дә алырга кирәк. Узган айда күпме тотылган, бу айда күпме сарыф ителгәнен чагыштырыгыз. Аңлашылмаучанлыклар булса, идарәче оешмага мөрәҗәгать итегез. Проблемагыз хәл ителми икән, торак инспекциясенә яки прокуратурага хәбәр итәргә кирәк, – дип киңәш бирә ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Гөлгенә ШИҺАПОВА

СОҢГЫ ЮЛ ХАКЫ

РОССИЯДӘ МӘЕТ ҖИРЛӘГӘНДӘ КҮРСӘТЕЛГӘН ХЕЗМӘТЛӘРГӘ БӘЯЛӘРНЕ ЙӨГӘНЛӘРГӘ ҖЫЕНАЛАР

Кеше кайгысында акча эшләп калырга теләүчеләргә чик куймакчылар. «Бердәм Россия» фракциясенә тапшырылган яңа закон проекты гамәлгә керә калса, ритуаль хезмәт күрсәтү тармагына тәртип салыныр дип өметләнәләр. Проект авторлары мәрхүмне җирләгән өчен бәяләрне йөгәнләргә тәкъдим итә.

Бүген Казанда ритуаль хезмәтләр күрсәтүче агентлык «ярдәме» уртача 4800 сумнан башлана. Монда катафалк машинасы белән мәетне алып бару өчен кабык (яки табут) бәясе кергән. Мәетне юып, җирләү документларын ук әзерләп бирүләрен теләсәң, бу сумма тагын да артачак. Һәр хезмәт өчен тагын уртача 3 мең сум акча өстисе булачак. Һәрхәлдә, «ВТ» элемтәгә кергән башкаладагы бер ритуаль агентлыкта әнә шулай дип аңлаттылар. Уртача алганда, бу эш 20 мең сумга төшә. Аңлашылганча, өстәмә хезмәтләр белән чыгымнар да арта.

Казанның Кадыш бистәсендә яшәүче Зөлфия Минһаҗева исә бу саннарга ышанып бетмәскә киңәш итте. Узган ел әтисен җирләгән ул. «Сентябрь аенда коронавирустан әтием вафат булды. Туган ягы – Апас районына алып кайтып җирләрсез, дип васыять иткән иде. Бер ритуаль агентлыкка шалтыратып, шулар ярдәменә генә таянырга булдым. Баштарак мәетне әзерләү, алып кайту чыгымнары 25 мең сумга төшәчәк дип санаганнар иде. Авылга кайтып җиткәнче бу сумма 35 мең сумга җитте. Тегесен әйтергә оныткабыз, монысының бәясен дөрес әйтмәгәнбез, дип акландылар. Аны уйлап торыр чак идемени, күпме сорадылар, шуның кадәр түләдем инде», – ди Зөлфия ханым.

Яңа закон әнә шундый аңлашылмаучанлыкларны кисәтер дип көтелә. Ул гамәлгә керә калса, ритуаль хезмәтләрне моның өчен рөхсәт алган агентлыклар гына күрсәтә алачак. Аларны махсус реестрга кертәчәкләр. Биредә алар башкарган эш тә, бәясе дә күрсәтеләчәк. Шушы ук реестрга үз эшен намус белән башкармаган ритуаль агентлыкларны да кертергә җыеналар. Моннан тыш ритуаль хезмәтләргә дә ил күләмендә уртача бәя билгеләргә җыеналар. Монда документлар әзерләп бирү, мәетне соңгы юлга озату өчен кирәк-ярак бирү, аны зиратка алып кайту, җирләү кебек төп хезмәтләр турында сүз бара. Кайбер төр хезмәтләр бушлай күрсәтеләчәк. Моның өчен хөкүмәт ритуаль агентлыкка 6964 сум күләмендә компенсация түләячәк. Аның күләме ел саен индексацияләнер дип көтелә. «Ритуаль хезмәтләр базарын көйләү бу өлкәдәге бәяләрне дә йөгәнләячәк. Юкса бүген күп кенә шәхси оешмалар үз хезмәтләре өчен чамадан тыш зур сумма сорый. Араларында бушлай күрсәтелергә тиешле хезмәтләр өчен дә акча сораучылар бар», – ди проект авторларының берсе, Дәүләт Думасы депутаты Светлана Разворотнева.

«Татар-информ»

Яңа закон проекты буенча үз эшен намус белән башкармаган, хәрәмләшкән ритуаль агентлыклар җәзага да тартылачак. Әйтик, рөхсәте булмаган килеш ритуаль хезмәт күрсәтсә, аңа 50–150 мең сум күләмендә штраф салыначак. Вазыйфаи затларга моның өчен – 100–200 мең сум, юридик затларга 1 млн сумга кадәр штраф чәпәргә җыеналар.

Татарстан Диния нәзарәтенең мәетләр җирләү буенча хезмәте җитәкчесе Рамил хәзрәт Мингәрәев тәкъдим ителгән яңа закон проектына уңай карый.

– Бу өлкәдә эшләүче барлык оешмаларны да намуссыз эшли дип әйтергә ярамый. Араларында, билгеле, кеше кайгысын уйламаган, хәлгә керә белмәгән, Аллаһ ризалыгы өчен түгел, ә акча өчен эшләүчеләр дә юк түгел. Әмма үз хезмәтләрен җиренә җиткереп башкаручылар да бар. Шуңа күрә эшчәнлекләрен тикшермичә-өйрәнмичә, нәтиҗә чыгару һәм яла ягу дөрес түгел. Дин кардәшләргә ышанычлы оешмаларга гына мөрәҗәгать итәргә киңәш итәм. Мисал өчен, рәсми рәвештә эшләгән мәчетләргә һәм имамнарга, – ди Рамил хәзрәт. – Гадәттә якыннарны җирләү мәсьәләсе килеп баскач, кайгыдан югалып калган кешеләр тиз арада эшне оештыруга мохтаҗлык кичерә. Шундый вакытта ярдәм итәр өчен, Татарстан мөфтиятенең мәетләр җирләү хезмәте эшли. Безнең белгечләр мәрхүмнең туганнарына мәет озатуны оештыруның теләсә кайсы этабында ярдәм итәчәк һәм ислам кануннары буенча күмү эшләрен һәм йолаларын гамәлгә ашырачак. Әлеге хезмәт тәүлек буе эшли.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ КАРАРЫ

гражданин Т.Ә. Вәлиев шикаятенә бәйле рәвештә Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче – бишенче абзацларының, үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы аерым нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча

Казан шәһәре 2022 елның 27 гыйнвары

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең

1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып, ачык суд утырышында Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче — бишенче абзацларының, үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы аерым нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин Т.Ә. Вәлиев шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Ф.С. Мусин мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе башлыгының беренче урынбасары Л.Р. Шәрипова, шикаять белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле үтенечнамәсе буенча суд утырышына чакырылган белгеч – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенең муниципаль торак фондын исәпкә алу һәм бүлү бүлеге башлыгы Е.Н. Смагина аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Т.Ә. Вәлиев Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең (алга таба шулай ук – Нигезләмә) 4.1 пунктындагы икенче – бишенче абзацлары, үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы аерым нигезләмәләр белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче – бишенче абзацлары нигезендә маневр фондының торак урыннары Россия Федерациясе Торак кодексының (алга таба шулай ук – Торак кодексы) 88, 106 статьяларында каралган очракларда һәм нигезләрдә маневр фондының торак урынын яллау килешүе буенча түләү хисабына түбәндәге чорга вакытлыча файдалануга бирелә:

1) муниципаль торак фондында социаль наем килешүләре буенча алар биләгән торак урыннар урнашкан йортка ясала торган капиталь ремонт яисә реконструкция тәмамланганчы;

2) түләттерү мөрәҗәгате нәтиҗәсендә банк яисә башка кредит оешмасы кредиты яки юридик зат тарафыннан торак урын сатып алуга бирелгән максатчан заем акчалары хисабына сатып алынган һәм кредитны яки максатчан заемны кайтаруны тәэмин итәр өчен залогка салынган торак урыннарын югалткан гражданнар белән исәп-хисаплар тәмамланганчыга кадәр, әгәр түләттерү мөрәҗәгате килгән вакытка мондый торак урыннар алар өчен бердәнбер торак урын булса;

3) бердәнбер торак урыны гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксызга әйләнгән гражданнарга.

Нигезләмәнең 4.2 пункты маневр фондының торак урыннары гражданнарга гариза нигезендә яки муниципаль торак фонды белән идарә итә торган оешманың реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау турында мөрәҗәгате яки залог тотучы булып торучы юридик зат мөрәҗәгате (алга таба – оешма мөрәҗәгате) нигезендә бирелүен күздә тота.

Нигезләмәнең 4.4 пункты нигезендә маневр торак фондыннан торак урын бирү турында гражданнарның гаризалары һәм оешмаларның мөрәҗәгатьләре кергән көннән алып 30 көн эчендә Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле органы (алга таба шулай ук вәкаләтле орган) тарафыннан карап тикшерелә; кабул ителгән карар турында гражданнарга һәм оешмаларга әлеге карар кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә язма рәвештә хәбәр ителә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, Т.Ә. Вәлиев үзенең хатыны, кызы һәм аның балигъ булмаган өч баласы белән гомуми мәйданы 26,05 кв. м булган тулай торак бүлмәсендә теркәлгән. Аның аз керемле дип танылган гаиләсе торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак 2010 елның 19 февраленнән исәптә торган. Үзенең социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны алу перспективалары юк дип уйлап, мөрәҗәгать итүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсенә үз гаиләсен маневр фондының торак урыннары белән тәэмин итү турындагы гаризасы белән мөрәҗәгать иткән, әмма, Казан шәһәрендә гражданнарга вакытлыча яшәү өчен маневр фонды булдырылмавына бәйле рәвештә, аңа баш тартылган. Гражданин Т.Ә. Вәлиев әлеге баш тартуны законсыз дип саный, чөнки баш тарту өчен мондый нигез Нигезләмәдә каралмаган.

Мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә игътибар итә: Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы шикаять белдерелә торган икенче – бишенче абзацларындагы аерым нигезләмәләре белән билгеләнгән маневр фондының торак урыннарын яллау килешүе буенча түләү хисабына вакытлыча файдалануга бирү чорларын билгеләүче хокукый җайга салу, фактта, мондый торак урыннары алу хокукына ия гражданнар категорияләренең тулы исемлеген беркетә, шул ук вакытта, Торак кодексының 95 статьясындагы төп нигезләмәләрен бозып, законда каралган очракларда башка гражданнарны исәпкә алмый, аларга, аның фикеренчә, ул үзе дә кертелергә мөмкин. Шул нигездә гражданин Т.Ә. Вәлиев дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрне җирле үзидарә органнары карарларының законлы характеры турындагы конституциячел нормага туры килми дип саный.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Нигезләмәнең 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы үзара бәйле нормалары, маневр фондының торак урыннарын бирү процедурасын билгеләп, шуның белән бергә гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча нинди нигезләрдә һәм нинди карарлар кабул ителергә мөмкин булуын күз алдында тотмый. Аның фикеренчә, күрсәтелгәннәр вәкаләтле орган тарафыннан тиешле карарны үзенә ирекле тәртиптә кабул итү мөмкинлеген калдыра, бу хокукый билгеләнмәгәнлек, тигезлек һәм гаделлекнең конституциячел принципларын бозуга китерә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Т.Ә. Вәлиев Татарстан Республикасы Конституция судыннан Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче – бишенче абзацларын, үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы аерым нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче өлеш) һәм 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре – иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау – Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы – сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә бүтән органнар компетенциясенә кергән барлык очракларда фактларны хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану гамәлиятендә аңа бирелгән мәгънәдән чыгып, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, ул буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллегенә шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора:

– Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче – бишенче абзацларындагы аерым нигезләмәләре, алар, гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү чорларын билгеләп, гражданны шушы чорлар кысаларында мондый торак урыннарын алу хокукына ия булган теге яки бу категориягә кертү өчен норматив нигез булып торган дәрәҗәдә;

– Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктлары, аларда гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү турында гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча нинди карарлар кабул ителергә мөмкинлеге мәсьәләсендә билгесезлек булган дәрәҗәдә.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау һәм торак законнары өлкәсенә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләр).

Торак законнары өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтләрен, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә вәкаләтләрен законнар белән бүлешү Торак кодексында беркетелгән, аның 5 статьясындагы 2 өлешендә торак турындагы законнар шул исәптән җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларыннан тора дип билгеләнгән.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 10, 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьялары нигезендә Татарстан Республикасында җирле үзидарә таныла һәм гарантияләнә, ул үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне халыкның хәл итүен, муниципаль милек биләүне, аннан файдалануны һәм аның белән эш итүне тәэмин итә, җирле үзидарә органнары муниципаль милеккә мөстәкыйль идарә итәләр. Тиңдәш нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 12, 130 (1 өлеш) һәм 132 статьяларында беркетелгән.

Күрсәтелгән хокукый җайга салу 1985 елның 15 октябрендәге Европа җирле үзидарә хартиясе (Россия Федерациясе өчен 1998 елның 1 сентябрендә үз көченә кергән) нигезләмәсе тәңгәл килә, аның нигезендә җирле үзидарә органнары үзләренең вәкаләтләре өлкәсендә законнар һәм нинди дә булса башка хакимият органы карамагында булмаган теләсә нинди мәсьәлә буенча үз инициативасын гамәлгә ашыру өчен законда билгеләнгән чикләрдә тулысынча ирекле эш итәләр (4 статьяның 2 пункты).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, карамактагы мәсьәләләрне, вәкаләтләрне һәм компетенцияне кертеп, җирле үзидарәнең хокукый нигезен билгели һәм җирле үзидарә оештыруның гомуми принципларын җайга сала. Әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 6 пунктлары нигезләмәләре шәһәр округының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә шәһәр округының муниципаль милкендәге мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү, шулай ук торак законнары нигезендә торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын тоту, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кертелгән.

Шуңа охшаш җайга салу «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 6 пунктларында каралган.

Торак кодексының 14 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә шул исәптән махсус муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү тәртибен билгеләү вәкаләте керә.

Федераль һәм республика законнарының китерелгән нигезләмәләре Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставында (алга таба шулай ук – Устав) үсеш алган, ул Казан шәһәре Думасы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы вәкаләтләре исәбенә Казан шәһәре муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен һәм махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибен билгеләү вәкаләтләрен кертә (28 статьяның 1 өлешенең 5 пункты).

Уставның күрсәтелгән нигезләмәләре нигезендә Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән «Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында» Нигезләмә расланган.

Шулай итеп, дәгъвалана торган норматив хокукый актны кабул итеп, Казан шәһәре Думасы федераль һәм республика законнары нигезендә үзенә караган һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының җайга салуы нигезләмәләренә нигезләнгән үз вәкаләтләрен законлы рәвештә гамәлгә ашырган.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), һәркемнең торакка хокукын беркетә; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья). Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, шул исәптән аның 7 һәм 40 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында билгеләнгән.

Әлеге конституциячел нормалар 1948 елның 10 декабрендәге Кеше хокуклары гомуми декларациясенең 25 статьясы һәм 1966 елның 16 декабрендәге Икътисадый, социаль һәм мәдәни хокуклар турында халыкара пактның 11 статьясы нигезләмәләренә тәңгәл килә, алар, лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук элементы буларак, һәркемнең торакка хокукын таныйлар.

Торак кодексының 2 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары гражданнарның торакка хокукларын гамәлгә ашыру өчен үз вәкаләтләре чикләрендә шартлар тәэмин итәләр, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль торак фондыннан торак урыннары яллау шартнамәләре буенча гражданнарга билгеләнгән тәртиптә торак урыннары бирәләр (3 пункт).

3.1. Торак кодексы «торак фонды» конституциячел-хокукый төшенчәсен конкретлаштырган (Россия Федерациясе Конституциясенең 40 статьясындагы 3 өлеш) һәм аны Россия Федерациясендәге барлык торак урыннары бергәлеге буларак билгеләгән (19 статьяның 1 өлеше); әлеге фондның бер өлеше – махсуслаштырылган торак фонды, ул гражданнарның аерым категорияләре яшәү өчен билгеләнгән дәүләт һәм муниципаль торак фондлары торак урыннары бергәлеге (19 статьяның 3 өлешендәге 2 пункты), аларга маневр фондындагы торак урыннар керә (92 статьяның 1 өлешендәге 3 пункты).

Торак кодексының 95 статьясы нигезендә маневр фондындагы торак урыннар түбәндәгеләргә вакытлыча яшәп тору өчен билгеләнә: гражданнарга социаль яллау шартнамәләре буенча алар били торган торак урыннар урнашкан йортка капиталь ремонт ясауга яисә аны үзгәртеп коруга бәйле рәвештә (1 пункт); банк яисә бүтән кредит оешмасы исәбеннән йә торак урыны алу өчен юридик зат тарафыннан бирелгән максатчан заем акчалары исәбеннән алынган һәм кредитны яисә максатчан заемны кире кайтаруны өчен закладка салынган торак урыннарын түләүгә алу нәтиҗәсендә торак урыннарын югалткан гражданнар, әгәр түләүгә алу вакытына мондый торак урыннар алар өчен бердәнбер булса (2 пункт); гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә бердәнбер торак урыннары яшәү өчен яраксыз булып калган гражданнарга (3 пункт); күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану нәтиҗәсендә торак урыннары яшәү өчен яраксыз булып калган гражданнарга (3.1 пункт); шулай ук законнарда каралган очракларда башка гражданнарга (4 пункт). Әлеге нигезләмәләр гражданнарның югарыда китерелгән һәр категориясе белән маневр фондының торак урыннарына наем шартнамәләре төзелә торган чорларны билгеләгән Торак кодексының 106 статьясы белән тыгыз элемтәдә тора.

Шулай итеп, федераль закон чыгаручы тарафыннан гражданнарның маневр фондының торак урыннарын алу хокукы барлыкка килә торган очраклар һәм нигезләр, мондый гражданнар категорияләре исемлеге, шулай ук аларның мондый торак урыннардан файдаланырга хокуклары булган чорлар билгеләнгән. Шуның белән бергә, гражданнарның аталган исемлеге тулы түгел, чөнки Торак кодексының күрсәтелгән нормалары маневр фондының торак урыннарын законнарда каралган башка очракларда да бирү мөмкинлеген калдыралар.

Торак кодексының китерелгән нигезләмәләре маневр фонды торак урыннарының социаль ярдәм чаралары буларак вакытлыча яшәү өчен гражданнарның аерым категорияләренә мондый торак урыннары бирүдән гыйбарәт булган хокукый режимы үзенчәлекләрен беркетәләр һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе торак законнары белән беркетелгән махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар, шул исәптән маневр фондының торак урыннарын бирү тәртибен билгеләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен закон нигезен тәшкил итәләр, моның дәвамы буларак, дәгъва белдерелә торган Нигезләмә белән Казан шәһәре Думасы маневр фондының торак урыннарын бирү тәртибен билгеләгән.

Үзенең хокукый эчтәлеге буенча Нигезләмәнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү чорларын күздә тоткан 4.1 пунктындагы икенче – бишенче абзацлары бланкет характерга ия, чөнки, аерым алганда, Торак кодексының югарыда аталган 106 статьясына сылтаулы нигезләмә бар. Әмма карала торган нормалар әлеге статьяның 2 өлешенең шул ук Кодексның 95 статьясы белән үзара бәйләнешендәге таләпләре белән тулысынча туры килеп бетми, чөнки алар күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану нәтиҗәсендә торак урыннары яшәү өчен яраксызга әйләнгән гражданнарга, шулай ук законнарда каралган очракларда башка гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү чорларын үз эченә алмый.

Нигезләмәдә кулланылган дәгъва белдерелә торган нормаларны бәян итүнең юридик конструкциясе вәкаләтле органга гражданнарны маневр фондының торак урыннарын бирү максатларында нормаларның бланкет характерын билгели торган таләпләрне исәпкә алмыйча теге яки бу категориягә кертү өчен, бердәнбер хокукый нигез буларак, алар тарафыннан билгеләнгән чорлар исемлеген кулланырга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, китерелгән туры килмәү нәтиҗәдә гражданнарның нинди категорияләре мондый торак алуга хокуклы булуын аңлауның һәм аңлатуның чикләү характерын алдан билгели, чөнки дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрдә беркетелгән чорлар исемлеге, шулай ук маневр фондының торак урыннарын бирү очраклары зур юридик көчкә ия булган норматив хокукый актта билгеләнгән шундый ук исемлек белән чагыштырганда сизелерлек кыскартылган, бу норматив хокукый актларның иерархиясен боза һәм вәкаләтле орган тарафыннан нигезсез һәм объектив булмаган карар кабул итүгә китерергә мөмкин.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Конституция суды гамәлдәге хокукый җайга салу системасында шикаять белдерелә торган нормалар, фактта маневр фондының торак урынын алу хокукына ия гражданнар категорияләренең тулы исемлеген билгеләп, аны бирү мәсьәләсен хәл итүгә төрлечә якын килергә, шулай ук аларны ирекле кулланырга мөмкинлек бирә, бу хокукый норманың ачыклыгы һәм бер мәгънәдә булуы гомумхокукый критерийларына туры килми һәм, димәк, тигезлек һәм гаделлек конституциячел принцибын боза, дигән нәтиҗәгә килә.

Россия Федерациясе Конституция Суды үзенең карарларында хокукый норманың билгелелеге таләбен бозу үзеннән-үзе мондый норманы Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килә дип тану өчен тулысынча җитәрлек булырга мөмкин дип берничә тапкыр билгеләп үтте (2011 елның 20 декабрендәге 29-П номерлы, 2015 елның 2 июнендәге 12-П номерлы, 2017 елның 19 июлендәге 22-П номерлы, 2018 елның 16 мартындагы 11-П номерлы һ.б. карарлар). Шуның белән бергә дәгъва белдерелә торган Нигезләмәнең 4.1 пунктының Торак кодексының югарыда китерелгән нормаларына карата субсидиар характерда булуын исәпкә алмыйча ярамый, бу гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү очракларын, нигезләрен, алар әлеге торак урыннарыннан файдаланырга хокуклы булган чорларны, шулай ук ачык булган һәм законда каралган очракларда гражданнарның башка категорияләренә торак урыннары бирү мөмкинлеген күздә тоткан мондый гражданнар категорияләре исемлеген төгәл беркеткән әлеге Кодексның 95 һәм 106 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренең турыдан-туры гамәлдә булуын күздә тота. Моннан чыгып, Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы шикаять белдерелә торган икенче – бишенче абзацларында эчтәлеге буенча Торак кодексы нигезләмәләренә охшаш хокукый нормаларның булмавы үзеннән-үзе соңгылары Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һичшиксез кулланылырга тиеш түгел дигәнне аңлатмый.

Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды, акыллы тотнаклылык принцибына таянып һәм объектив килеп туган чынбарлыкны исәпкә алып, конституциячел яклана торган кыйммәтләр балансын саклау максатларында әлеге эштә Нигезләмәнең

4.1 пунктындагы икенче – бишенче абзацының аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып калырга мөмкин дип саный, чөнки дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрне хокук өлкәсеннән төшереп калдыру гражданнарның Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә аларның маневр фондының торак урыннарын алу хокукларын нигезсез рәвештә чикләүгә китерергә мөмкин.

Моның белән Казан шәһәре җирле үзидарә вәкиллекле органыннан, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып, гражданнарның аерым категорияләренә беркетелгән маневр фондының торак урыннарын алу хокукы шик астына куелмасын өчен, ә хокук куллану практикасында дәгъва белдерелә торган хокукый нормаларны каршылыклы аңлату булмасын өчен шикаять белдерелә торган актка үз вакытында Торак кодексы нигезләмәләреннән һәм әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләр кертү бурычы алынмый.

3.2. Нигезләмәнең 4.2 һәм 4.4 пунктларының үзара бәйле нормалары, үзләренең асылы буенча, гражданнарның Казан шәһәре маневр фондының торак урынын алуга хокукын гамәлгә ашыруның оештыру-процедура механизмы элементлары буларак, гражданнар яисә оешмаларның мөрәҗәгать итүе гариза тәртибендә булуын (4.2 пункт), мондый мөрәҗәгатьләрне карау срокларын, шулай ук кабул ителгән карарлар турында гражданнарга һәм оешмаларга хәбәр итү срокларын һәм ысулын күздә тота (4.4 пункт).

Күрсәтелгән нигезләмәләрнең конституциячеллегенә дәгъва белдереп, гражданин Т.Ә. Вәлиев аларда закон белән билгеләнгән хокукны гамәлгә ашыру максатларында мөрәҗәгать иткән гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау процедурасы кысаларында вәкаләтле орган тарафыннан үтәлергә тиешле тулы бер эзлекле гамәлләрнең булмавын күрә. Аның фикеренчә, Нигезләмәдә гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча нинди нигезләрдә һәм нинди карарлар кабул ителергә мөмкин булуы турында сорауларга җавап бирә торган нормалар чагылыш тапмаган.

Шуның белән бергә Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгать итүченең дәлилләре белән килешә алмый, чөнки шикаять белдерелә торган нормаларны маневр фондының торак урыннары гражданнарга Казан шәһәре Башкарма комитеты карары буенча бирелүен күздә тоткан Нигезләмәнең 1.4 пункты белән, граждан тарафыннан вәкаләтле органга тапшырылырга тиешле документлар исемлеген билгеләүче Нигезләмәнең 4.3 пункты белән, шулай ук гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү очракларын һәм нигезләрен ачыклаучы Торак кодексының 95 статьясы белән үзара бәйләнештә Нигезләмәнең 4.1 пункты белән аерылгысыз бердәмлектә карарга кирәк. Китерелгән җайга салу белән гамәлләр алгоритмын үтәү зарурлыгы таләп ителә, аның буенча вәкаләтле орган, граждан гаризасын яисә оешма мөрәҗәгатен кабул итеп, вакытлыча яшәү өчен маневр фондының торак урыннарын алуга нигез булган хәлләрне, шулай ук Казан шәһәрендә гражданның торак урыннар белән тәэмин ителешенә карата гаризага кушып бирелгән документларны бәяли һәм билгеләнгән срокта тиешле карар кабул итә. Шул ук вакытта Торак кодексы һәм Нигезләмә нормаларыннан килеп чыга торган хәлләрнең норматив-хокукый характеристикасы вәкаләтле орган тарафыннан кабул ителә торган гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү турында гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен канәгатьләндерү турында да, канәгатьләндерүдән баш тарту турында да карарларның дәлилләнгән булуын алдан билгели.

Димәк, гражданин Т.Ә. Вәлиев тарафыннан дәгъва белдерелә торган нормалар үзеннән-үзе гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү турында гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча нинди карарлар кабул ителергә мөмкин булуы турындагы мәсьәләдә билгесезлек юк һәм хокук куллану практикасында әлеге хокукый җайга салу белән ярашмый торган башкача аңлатуга юл куймыйлар һәм вәкаләтле орган тарафыннан дәлилләнмәгән уңай карарны да, тискәре карарны да кабул итү мөмкин булган аларның мондый кулланылышын кире кагалар. Гавами хакимиятнең тиешле органы торакларын югалтуга китергән тормыш хәлендә калган яки капиталь ремонт яисә реконструкцияләүгә бәйле рәвештә торак урынында яшәү мөмкин булмаган гражданнар вакытлыча файдалануга маневр фондының торак урынын алуның реаль мөмкинлегенә ия булсын өчен, шулай ук әлеге социаль ярдәм чарасын иллюзор характерда булмаслык итеп тормышка ашыруны тәэмин итәр өчен барлык тиешле чараларны күрергә тиеш.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге нәтиҗәгә килә: гамәлдәге хокукый җайга салу системасында гражданнарның Казан шәһәре маневр фондының торак урынын алуга хокукын гамәлгә ашыруның оештыру-процедура механизмы элементлары булган Нигезләмәнең 4.2 һәм 4.4 пунктларындагы үзара бәйле нормалар, үзләренең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча вәкаләтле органның шикаять белдерелә торган норматив хокукый акт белән билгеләнгән срокларда маневр фондының торак урынын бирү яки аны бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар кабул итәргә тиеш булуын күздә тота һәм шуның белән карала торган аспектта билгесезлек юк, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

Шуның белән бергә, гражданнарга Казан шәһәре маневр фондының торак урыннарын бирү турында гражданнарның гаризаларын яки оешмаларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен билгели торган нигезләмәләрне бертөрле куллану максатларында Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге хокукый җайга салуны камилләштерү мәсьәләсен тиешле карар кабул итү процедурасын тагын да тулырак регламентлаштыруга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү юлы белән анда кабул ителгән карарны дәлилле нигезләүнең мәҗбүрилегенә турыдан-туры күрсәтмәсен чагылдырып карау максатка ярашлы дип саный. Мондый үзгәрешләр дәгъва белдерелә торган нормаларның ирекле кулланылышын кире кагарлар иде һәм бу мәсьәләдә мөнәсәбәтләрне җайга салуда ачыклык, төгәллек булуга һәм бер мәгънәдә аңлауга ярдәм итәр иде. Хәзерге вакытта гамәлдә булган маневр фондының торак урынын наемга алу шартнамәсе буенча торак урыннар бирү тәртибен, маневр фондының торак урынын алуга гариза формасын да кертеп (1 номерлы кушымта), гаризаларны карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның төрләрен, шулай ук маневр фондының торак урынын бирүдән баш тарту өчен нигезләрне билгеләүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1314 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең маневрлы муниципаль торак фондын төзү турында нигезләмә белән күрсәтелгән үзгәрешләр кертү зарурлыгы юкка чыгарылмый. Мондый алым Уставның 40 статьясындагы 3.8 пункты нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренә мондый торак урыннарны бирү генә кертелгән булуы, ә махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибен һәм маневр фондының торак урыннарын бирү процедурасының үзен билгеләү Уставның 28 статьясы нигезендә Казан шәһәре Думасының аерым компетенциясе булып торуы белән бәйле. Шуның белән бергә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1314 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең маневрлы муниципаль торак фондын төзү турында нигезләмәнең, шул исәптән гамәлдәге хокукый җайга салу системасында аның урыны һәм аны кабул итү тәртибе күзлегеннән, конституциячеллегенә алга таба бәя бирү мөмкин түгел, чөнки бу норматив хокукый акт әлеге эштә Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тормый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

карар чыгарды:

1. Әлеге эштә Татарстан Республикасы Конституция суды Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең 4.1 пунктындагы икенче – бишенче абзацының аерым нигезләмәләрен, гражданнарга маневр фондының торак урыннарын бирү чорларын билгеләп, алар гражданны шушы чорлар кысаларында мондый торак урыннарын алу хокукына ия булган теге яки бу категориягә кертү өчен норматив нигез булып торган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала.

Моның белән Казан шәһәре җирле үзидарә вәкиллекле органыннан, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып, гражданнарның аерым категорияләренә беркетелгән маневр фондының торак урыннарын алу хокукы шик астына куелмасын өчен, ә хокук куллану практикасында дәгъва белдерелә торган хокукый нормаларны каршылыклы аңлату булмасын өчен шикаять белдерелә торган актка үз вакытында Россия Федерациясе Торак кодексы нигезләмәләреннән һәм әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләр кертү бурычы алынмый.

2. Казан шәһәре Думасының 2006 елның 1 ноябрендәге 11-13 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең махсус муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында нигезләмәнең үзара бәйле 4.2 һәм 4.4 пунктларын, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 103-П **Татарстан Республикасы Конституция суды**

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Спорт

Күрәселәр бар әле

Пекиндагы Кышкы Олимпия уеннары ахырына якынлаша. Бу ярышлар Россия җыелма командасы өчен уңышлы да, борчулы да булып истә калыр, мөгаен. Безнекеләргә ярышта гына түгел, медаль өчен киңәшмәләр бүлмәсендә дә көрәшергә туры килә. Бәхәс әле дәвам итәчәк.

Чираттагы карар

Олимпия уеннарында чыгыш ясаучы иң яшь спортчыларның берсе, 15 яшьлек татар кызы Камилә Вәлиевага бу көннәрдә хаксызлык, социаль челтәрләрдәге имеш-мимешләр һәм журналистларның уйланмый әйтелгән сүзләренә каршы торырга туры килде. Ялган мең булса да, бер хаклыкны җиңә алмый, дигән безнең халык. Камиләбезнең дә чиста һәм хаклы булуына ышанабыз без. Ә аны нәрсә өчен, ни сәбәпле гаепләүләрен кабат искәртеп торуның кирәге юктыр – бу турыда белмәгән, ишетмәгән, яшь спортчы өчен җан атмаган кеше бармы икән арабызда?

Шөкер, дүшәмбе иртәсендә барыбыз да җиңел сулап куйгандыр. Спорт арбитражы суды (CAS) 15 яшьлек татар кызына шәхси турнирда чыгыш ясарга рөхсәт бирде. Тикшерү 7 сәгать дәвам итте. Әлеге карар 15 яшьлек Вәлиеваның «якланылган зат» статусын (ул 16 яше тулмаган спортчыларга бирелә һәм аларга карата үзгә мөнәсәбәт булырга тиешлеген күздә тота) һәм декабрьдә алынган допинг-тест нәтиҗәләренең артык соң хәбәр ителүен исәпкә алып чыгарылган. Ләкин бу – соңгы карар түгел. Камиләнең допинг-тестына бәйле тикшерү эшләре дәвам итәчәк. Әлегә Россия фигуралы шуучыларның команда турнирында яулаган алтын медаленең дә язмышы хәл ителмәгән.

Ничек кенә булмасын, Камиләгә үзен күрсәтер өчен мөмкинлек бирелде. Хәер, аның көчле рухы, сынмас характеры инде күпләрне таң калдырды. Билгесезлек чорын кичергәндә дә, Камиләбез башын югары тотып, ихластан елмая белде. 15 яшьлек спортчыны күнекмәләр вакытында да күзәтеп торып, соңыннан тиешле-тиешсез сораулар «яудырган» журналистлар да, социаль челтәрләрдәге яман сүзләр дә бу елмаюга тап төшермәде. Ә кешеләр исә кабат ике төркемгә бүленде – каты бәгырьлеләр һәм аңларга сәләтлеләр сүз көрәштерде. Эшнең моның белән генә бетмәвенә ихластан сөенүчеләр дә аз түгелдер.

15 һәм 17 февральдә кызны шәхси ярышлар көтә. Шушы мизгелгә кадәр бирешмәгән Камиләбез, ничек кенә авыр булса да, бу юлы да сынатмас.

Яхшы хәбәрләр

Ул арада Россия спортчылары медальләр туплавын дәвам итте. Узган шимбәдә Юлия Ступак, Наталья Непряева, Татьяна Сорина һәм Вероника Степанова составындагы чаңгычылар җыелма командасы хатын-кызлар эстафетасында беренчелекне яулады. Вероника Степанова, ярышның соңгы минутларында Германия спортчысы белән узышып, тарихта Олимпия чемпионы булган иң яшь чаңгычы исеменә лаек булды.

Икенче көнне үк әлеге җиңүне ир-атлар җыелма командасы кабатлады. Чаңгы эстафетасында Алексей Червоткин, Александр Большунов, Денис Спицов һәм Сергей Устюгов чыгыш ясады. Безнекеләр Норвегия командасын 1,7 минутка артта калдырып, финишка беренче килде. Франция чаңгычылары өченче булды. Әйтергә кирәк, ир-егетләрнең чаңгы эстафетасында Россия спортчылары соңгы тапкыр 42 ел элек җиңгән булган.

Якшәмбе узган ярышларда татар егете Эдуард Латыйпов та сынатмады. Самара өлкәсенең Камышлы районында туып-үскән спортчы биатлон буенча 12,5 чакрым арага узышуда финишка өченче булып килде. «Спортчыларга аеруча авырга туры килде – көчле җил, суык комачаулады. Җанатарлар бу узышны истә калдырыр дип уйлыйм. Ярыш башланыр алдыннан егетләрнең чаңгы эстафетасындагы чыгышын карадым. Алар җиңгәч, без дә бирегә яхшы кәеф белән килдек. Узышка егетләр өчен куанып, җанатарларны сөендерү теләге белән чыктым. Соңгы минутлар киеренкелектә тотса да, үз максатыма ирештем», – дигән Эдуард ярыштан соң.

Медальләр моның белән дә бетмәде әле. Шорт-трек буенча ярышларда Россия спортчысы Константин Ивлиев – көмеш, ә тимераякта йөгерү буенча ярышларда Ангелина Голикова бронза медальләргә лаек булды.

Дүшәмбе иртәсе дә фигуралы шуучыларга уңыш китерде. Бозда биюче Виктория Синицина белән Никита Кацалапов көмеш медальгә лаек булды. Франция спортчылары – беренче, АКШ фигуралы шуучылары өченче урынны алды.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

МАТУРЛЫК ХАКЫНА

Модада – матурлык, яшьлек. Замана медицинасы кәкре борынны турайтырга, җыерчыклы битне яшәртергә, гәүдәдәге артык майларны киметергә ярдәм итә ала. Моннан биш ел элек республикада елына 3 мең пластик операция ясалса, бүген бу сан 10 меңгә җиткән. Тик пычак астына керү һәр очракта да хәерле тәмамланмаска мөмкин. Ничек матурлык корбанына әйләнмәскә?

Үзеңне яратырга кирәк

Күптән түгел Мәскәүдә пластик хирургия клиникасында Түбән Камада яшәүче 28 яшьлек кызның вафат булуын ишеттек. Ул гәүдәсендәге артык майлардан котылырга теләгән. Тик липосакция процедурасыннан соң йөрәге туктаган. Табиблар кызның гомерен саклап кала алмаган. Шул ук вакытта тән тиресен матурайтып, башларын горур тотып йөрүче ханымнар да аз түгел. Әнә Иҗау шәһәрендә яшәүче Фәридә Ракова да, җыерчыкларыннан котылгач, иркен сулап куйган. Хәзер аңа дөнья тагын да матуррак тоела икән.

– Блефаропластика ясатуымны кешедән яшермим. Син үзгәргәнсең, хәзер 10 яшькә яшьрәк күренәсең, диләр. Мактау сүзләрен ешрак ишетә башладым. Кайберәүләр хәтта, шундый зур балаларың бармыни, дип тә аптырый. Кеше арасында йөргәндә ышанычым артты. Карашым да ачык хәзер. Биттәге җыерчыклар өчен борчыласы юк. Күз төпләрендәге кара «капчык»лар да бетте, җөйләр дә калмады. Анда бүсер дә булган әле. Бу бит файдага түгел. Танышларыма, туганнарыма да, курыкмагыз, үзегезне яратыгыз, дим. 40 яшьтән соң бернинди крем да булышмый. Үзем дә – реанимациядә эшләгән шәфкать туташы бит мин. Шуңа күрә табибларга ышанам. Бит буенча проблема юк, хәзер муен тиресен генә тәртипкә китерәсе калды. Шуңа акча җыям, – ди ул.

Акчаң булса, хирурглар синнән 1–2 сәгать эчендә чибәр кеше ясый. Казандагы бәяләр дә тешләрлек түгел, ди. Күзнең аскы яки өске кабагына пластик операция ясату 50 мең сумга төшә. Наркоз өчен өстәмә 10 мең сум түләргә кирәк. Анализларны да бик тиз алалар, икенче көнне үк операциядән соң кайтып та китәргә була, дип мактый Фәридә ханым. Ике атнадан эшкә чыгарга, бизәнергә ярый икән.

Күңел яралары...

– Мәктәптә укыганда, борының карчыганыкы кебек, дип көләләр иде миннән. Шул күңелгә сеңеп калгангамы, гомер буе оялып яшәдем. Кияүгә чыккач та, бу читенсенүләр бетмәде. Мин – авыл кызы, ирем – шәһәрнеке. Аның таләпләре зур. Гәүдәмдә бер артык май да булмаска тиеш. Шуңа күрә көн саен күнегүләр ясарга кушты. Мин аның өчен зифа буйлы модель булдым. Артык ашарга ярамады, кәнфитләрдән тыелып тордым. Иремә моның өчен үпкәләмәдем. Борыным турында да гел төрттереп торды. Түземлегем озакка җитмәде, ун ел яшәгәч, аерылыштык. Тик бүген дә борынны нәфисләндерү уе тынгы бирми. Төрле клиникаларга барып, табиблар белешеп йөрим әле. 130 мең түләсәм, бик матур борын вәгъдә итәләр. Кредитка алып булса да төзәтәсе иде инде. Яхшы табиб кына табасы калды, – ди Казанда яшәүче 41 яшьлек Айсылу Закирҗанова.

Хатын-кызлар гына түгел, ирләр арасында да битләренә игътибар итүчеләр шактый. Кем өчендер биткә бетчә чыгу да – фаҗига. Ә инде нинди дә жәрәхәт... Монысы дөнья бетүгә тиң.

– Эштәге танышым, ачуы чыгып, өстәлдәге кайчыны йөземә тотып аткан иде. Ничек әле күзгә төртелмәде. Маңгайга очлы башы белән килеп бәрелде. Маңгай ярылды, тәре кебек эз калды. Мин бит – мөселман кеше. Берничә ай буе эчем пошып йөрдем. Бары пластик операция белән генә авыр хәлттән котылдым, – ди Алмаз.

Ә СЕЗ ПЛАСТИК ОПЕРАЦИЯ ЯСАТЫР ИДЕГЕЗМЕ?

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ, журналист:
– Мин табигыйлекне бозуга гомумән каршы. Телевизордан чабата иреннәрне күргәч тә гайрәт чигә. Андый иреннәрне мәңге үпмәс идем. Күзгә бик каты бәрелеп торган кимчелек булса гына кеше кыяфәтенә кертергә мөмкиндер дип уйлыйм. Табигый матурлыкка берни дә җитми.

Люция ХӘМИТОВА, Камал театры артисты:
– Артист, хатын-кыз буларак, тышкы кыяфәтне тәртипкә китерүгә мин каршы түгел. Әлбәттә, пластик операцияләрне хупламыйм, йөзгә ясатмас идем. Хәзер медицина югары дәрәҗәдә, пычаксыз да мөмкинлекләр җитәрлек. Битне чистарту, лазер терапияләре бар. Алар ярдәмендә дә бит тиресен матурайтып була.

Кая барганыңны белеп бар!

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш пластик хирургы, медицина фәннәре кандидаты Сергей Обыденновтан пластик операцияләрнең нәтиҗәләре, таләпләр турында кызыксындык. Бу эштә ул – 1992 елдан бирле. Үзе генә дә меңләгән кешенең проблемасын хәл иткән. Аның өчен иң катлаулысы – борын төзәтү.

– Кем нинди нәтиҗә көтә бит. Әлбәттә, 80 яшьлек әбидән 30 яшьлек кыз ясап булмый. Әмма 50 яшьлек итәргә була. Җыерчыклары кими, яшәреп китәләр. Күбрәк хатын-кызлар мөрәҗәгать итә, шул ук вакытта сирәк булса да, борын ясатучы, битләрен тарттыручы ирләр дә бар, – ди Сергей Обыденнов. – Блефаропластика, май алдыру иң популяр операцияләрдән санала. Кеше хәзер үз кыяфәтенә бик нык игътибар бирә. Соңгы елларда пластик операцияләр ясату өч тапкыр артты. Елның теләсә кайсы вакытын сайларга була, тик иң яхшысы – көз. Алдан әзерләнү кирәкми, иң мөһиме теләк булсын. Операцияләр 15 минуттан 6 сәгатькә кадәр сузылырга мөмкин. Май алдырамы, күз кабагын рәткә китерәме – бәяләр төрле. Күп дигәндә 100 мең сумга җитә. Әлбәттә, берничә урынга ясатсаң, хакы да арта. Тик кая барганыңны белеп барырга кирәк. Мондый операцияләрне медицина салонында ясарга ярамый. Табибның сертификаты, клиниканың лицензиясе булырга тиеш. Пластик хирургларга таләпләр зур. Берәүдән күреп, икенчесе килә. Клиника күптән эшләсә, «сарафанлы радио» булыша. Куркыныч түгел, теләге булганнар бара да ясата. Бездә күңелсез хәлләр булганы юк, шөкер. Пластик кына түгел, теләсә кайсы хирургиядә кан китү, гематомалар, катлаулы очраклар килеп чыгарга мөмкин. Без аларны булдырмаска тырышабыз. Мәскәүдәге хәлнең сәбәбен төгәл әйтә алмыйм. Андый очракларның наркозны артык биреп, аллергия китү, анестезиолог хатасы белән бәйле булуы бар. Биш, ун елга бер булуы ихтимал.

Сәрия МИФТАХОВА

pixabay.com

Фикер

Равил хәзрәт БИКБАЕВ, Әмәт бистәсе мәчете имам-хатыйбы:
– Ниндидер фаҗигадән соң кешенең йөзенә, колагына, борынына зыян килгәндә, гаепне төзәтү өчен операция ясатырга мөмкин. Бәлкем, монда гәүдәдәге артык майны киметүне дә кертеп буладыр. Артык майны бетерә алмаганда һәм бу сәламәтлеккә комачауласа, пластик хирургка мөрәҗәгать итәргә ярый. Әмма матурлык өчен ниндидер органны кечерәйтү яки зурайту, табигый хәлен үзгәртү рөхсәт ителми. Борынны нәфисләндерү, иренне күпертү рөхсәт ителгән эш түгел. Пәйгамбәребез каш йолкучы, теш араларын матурлык өчен үзгәртүчеләрне, Аллаһы Тәгалә бар иткән әйберне үзгәртергә тырышалар дип, хәдисләрендә ләгънәт кылды. Моны «Ән-Ниса» сүрәсенең 119 аятендә шайтан гамәленнән санады. Шайтан, кешеләрне үзләрен үзгәрттерер өчен котыртырмын, дигән. Аллаһы Тәгалә һәркемгә үз матурлыгын биргән, ирме, хатын-кызмы – тышкы халәтеннән читенсенмәскә тиеш. Бу – табигый матурлык.

Фирдәвес ДЕВЯТАЕВА, косметолог:
– Безнең компаниягә 29 ел була. Косметолог булып аңарчы ук эшли идем. Косметология ул – бизнес. Күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә беркайчан да үз товарыбызны кешегә такмыйм. Менә шундый кагыйдә буенча яшим. Бу бит – игълан. Һәр кешенең – үз бите, тән тиресе. Ул пластик операция ясатуын, нинди фирмадан крем алуын бары үзе генә хәл итә. Бу начар, бу әйбәт дип әйтә алмыйм. Моңа минем хакым юк. Сезнең тире – сезнең милек, дим. Хезмәтен дөрес башкарган пластик хирургларның эшенә сокланам. Әмма алар күп түгел. Беркайчан да пластик операция ясатканым, хәтта укол да кадатканым юк. Иремә рәхмәт әйтәм. Син бу кремнарны уйлап тапмасаң, әллә кайчан әби булып бетәр идем, дим. Чәшке мае кешенең тиресе белән охшаш. Крем кешене яшәртергә, суыктан, стресстан сакларга тиеш.

101 ЯШЬЛЕК ФАТЫЙМА ШАҺИВӘЛИЕВА:

«БУ ЯШЬТӘ ТАБИБКА БАРУ ОЯТ»

Гөлнур Хурамшинаның шәхси архивыннан

Соклану

Мамадыш районының Түбән Ушма авылында гомер итүче Фатыйма әби күптән түгел 101 яшен тутырды. Күпне күргән, күпне кичергән ул. Хыялы да бар: Курил утрауларын тагын бер барып күрәсе килә аның.

– Безнең әби 27 яшендә кияүгә чыга. Бабай хәрби кеше булгач, ул кая барса, әби дә шунда ияреп йөри. Кырыс холыклы бабай янәшәсендә барысын да җайлап-көйләп яши ул. Курил утравында яшәгән чакта өч балалары туа. Шуннан соң аларны туган якка кайтаралар. Монда кайткач, тагын биш балага гомер бирә алар. Кызганыч, ике туганыбыз исән түгел инде, – ди Фатыйма әбинең оныгы Гөлнур Хурамшина.

Әхмәтгали абый озын гомерле булмый. 1982 елда бакыйлыкка күчә. Фатыйма апа бүген дә аек акыллы, бөтен нәрсәне хәтерли, бер дә зарланмыйча яши. Ачлык елында туып, сугыш чорларын кичереп, күп авырлыклар күреп яшәгән ул. Холкы шундый – кешегә начар сүз әйтми, авыр бәрелми, зарланмый. Янында яшәүче уллары Якуб белән Наил дә әниләрен гел мактап тора.

– Без – бик бәхетле кешеләр. Әниле килеш картаябыз, бүген дә аның яратуын тоеп яшибез. Абыем – 73 яшендә, мин – туганнарның иң кечесе. Миңа да 58 инде. Әниле булуга ни җитә! Бергә табын янына җыелып чәй эчүләр ни тора! Әни сөйли, без тыңлыйбыз, – ди Наил абый.

Якуб абый да, Наил абый да гаилә кормаганнар. Башта ике туганнарының бер-бер артлы фаҗигале төстә һәлак булулары, аннары әтиләренең вафаты аларның тормышын үзгәртә. Якуб абый ир туганнарының үлемен авыр кичерә. Эш белән юанырга тырыша. Кайда авыр хезмәт – шунда чыгып китә. Казахстанга да барып эшли. Наил абый исә армиядән кайта да, әниләре ялгыз яшәмәсен дип, аның янына төпләнә. Иң кечесе бит. Бурычы шундый.

– Без, алты бала, бик тату яшибез. Туганнарыбыз кайтып ярдәм итеп тора. Әни үзе дә кызлар кебек әле. «Авырыйм» дигәне юк. Шушы яшькә җитеп, бер тапкыр да табибка барганы булмады. Туган көне белән котларга килгән район башлыгы Анатолий Иванов, күзем начар күрә дигәч, әнине үзе хастаханәгә алып барам дигән иде. Әни оялды. «Шушы яшемдә табиб эзләп йөрергә Аллаһы Тәгаләдән оят», – ди ул. Башка җире авыртмый. Хәтере дә бик яхшы. Рәхәтләнеп әллә кайчангыларны искә алып утырабыз, – ди Наил абый. – Әнинең белмәгәне юк. Легенда ул безнең. Авылда да тарихны өйрәнүче кешеләр безгә килә. Әле менә Якутиядән бер авылдашыбызның улы кайткан иде. Әтисенең нигезен эзли. 1937 елда авылдан чыгып киткән булганнар. Әни ул абыйның исем-фамилиясенә кадәр әйтеп биреп, торган урыннарын күрсәтте.

101 яшькә җитәр өчен, ничек яшәргә соң? Наил абый, озак яшәүнең сере – кешенең күңелендә, ди.

– Әни сигез бала үстереп тә, бер зарланмады. Колхозда төрле эшләрдә эшләде. «Арыдым» дип әйтә белмәде. Алты ай эчендә ике газизен салкын җир куенына салгач та, Аллаһы Тәгаләдән узып булмый, язмышлары шулдыр, дип сабыр итте. Калган балаларына догасын укып тора. Күршеләр белән дус яшәде. Көчле рухлы булды. Әле дә барыбызга үрнәк ул, – ди Наил абый. – Иртәнге биштә итле шулпа ашый ул. Аппетиты яхшы. Көн саен саф һавада йөри. Озак яшәгәнен белә. Әмма тормыштан туйдым дими. Һәр туар таңга рәхмәтен әйтеп, шөкер итә. Әле менә соңгы арада, гомер булмаганны, җырлый башлады. «Мәтрүшкәләр»не җырлаганны рәхәтләнеп тыңлап утырабыз. Җырласын гына да, яшәсен генә әле! Әни барда безгә бик рәхәт!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, әнисе

Огородникова Алевтина Тимофеевна

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәгълүмати технологияләр, элемтә һәм мәгълүматны саклау идарәсе башлыгы Огородников Алексей Игоревичның авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре, бертуганы

Сәмигуллин Айрат Васыйл улы

кинәт вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге баш белгеч-эксперты Шәйхетдинова Аида Васыйл кызының авыр кайгысын уртаклаша.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7080 данә
Гомуми тираж – 17126 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 222

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+